| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ХОЗЕСАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХУҖА ХӘСӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.04.2025ел Хуҗа Хәсән ав. №2

Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге бюджетыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм өч һәм аннан да күбрәк баш савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнары өлешен каплауга субсидия бирү тәртибе турында» 2021 елның 11 октябрендәге 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге бюджетыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм өч һәм аннан да күбрәк баш савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнары өлешен каплауга субсидия бирү тәртибе турында» 2021 елның 11 октябрендәге 9 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.8. пунктта «субсидияләр бирүчеләргә - Башкарма комитет һәм муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләрен тикшерүләр» сүзләрен «субсидияләр бирүчеләргә - Башкарма комитет һәм муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 3 пунктының 5 пунктчасында каралган тикшерүләр»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб – адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» һәм https://hozesan-kaybici.tatarstan.ru/ веб – адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Хуҗа Хәсән авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе С.П.Матвеева